ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**Постановление** **Карар**

16.07.2025 ел № 6

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге территориясендә эшләми торган терекөмешле лампаларны туплау урыны турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру булмаган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында, яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайван, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре» 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карарына туры китереп (алга таба-кагыйдәләр)

**КАРАР БИРӘМ**:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә,эшләми торган терекөмешле лампаларның, шул исәптән Кагыйдәләрнең 5 пункты нигезендә мондый туплау урынынын оештыру өчен күпфатирлы йортларда урын булмау сәбәпле, туплау урыннарын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге территориясендә эшләми торган терекөмешле лампалар туплау урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, мәгълүматны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга мәгълүмат җиткерергә

:

Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Урман Асты Шонталасы авылы, Г.Тукай ур., 42 йорт;

Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Арбузов Баран авылы, Чернышевский ур., 14а йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында: https://alekseevskiy.tatarstan.ru.урнаштырылырга тиеш.

4. Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Башкарма комитетының 24.10.2016 ел, №18 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә эшләми торган терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыны турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А. Ә. Җиһаншин**

Алексеевск
муниципаль районы Урман Асты Шонталасы
авыл җирлеге Башкарма
комитетының 16.07.2025 ел, № 6
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге территориясендә эшләми торган терекөмешле лампалар туплау урыны**

| № т/б | Бина | Адрес |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитеты | Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Урман Асты Шонтала авылы, Габдулла Тукай ур., 42 йорт. (тел. 843414-11-00) |